СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

31.10.2025 № 2/5

На №__________от_______________

# КАРАР

## «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, Тукай муниципаль районы уставы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2025 елның 29 сентябрендәге 01-09.22309 номерлы хатын, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» 2025 елның 13 февралендәге 122/о номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2023 елның 10 июлендәге 34/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегенең генераль планын гамәлдән чыгарырга.
2. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2023 елның 10 июлендәге 34/2 номерлы карары үз көчен югалткан дип таныргa.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштырырга.
4. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет рәисе урынбасары

Р.И. Закиров